**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 6 апрель | № 219

г. Казань

Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Тәртипне куллану буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 6 апрель, 219 нчы
карары белән расланды

**Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә халыкның эш белән тәэмин ителеше турында» 1991 ел, 19 апрель, 1032-1 нче Россия Федерациясе Законын, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында» 2006 ел, 19 июнь, ТРЗ-39 нчы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 162 нче карары белән расланган «2015 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында эшләнде.

2. Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына 2015 елда субсидияләр бирү һәм бүлү турында» 2015 ел, 22 гыйнвар, 35 нче карары нигезендә эшләнде.

3. Тәртип оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү күләмен һәм механизмын билгели.

4. Оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән шартнамә төзегән «2015 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасында катнашучы булган эш бирүчегә гамәлгә ашырыла.

Компенсацияләү эш бирүчегә вакытлыча эшләргә урнаштырылган түбәндәгеләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын, шул исәптән 2015 елның 30 мартыннан тотылган чыгымнарын каплау максатларында гамәлгә ашырыла:

оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган (тулы булмаган эш вакыты билгеләү, эшләрне вакытлыча туктатып тору, эш хакын сакламыйча яллар бирү, хезмәткәрләрне эштән азат итү чаралары үткәрелү) хезмәткәрләренең;

эш эзләүче гражданнарның.

5. Вакытлыча эшкә урнашу төшенчәсен вакытлыча характердагы эш урыннарына, шул исәптән төрле квалификациядәге хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен читтән килеп һәм оешма эчендә берьюлы берничә эштә эшләү шартларында эшкә урнашу дип аңларга кирәк.

6. Бер айда бер кешенең хезмәт өчен түләвен компенсацияләү күләме, эшкә яраклы халык өчен Татарстан Республикасында 2014 елның IV кварталында билгеләнгән яшәү минимумының бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре суммасына арттырылган күләменнән чыгып, предприятиедә гамәлдә булган хезмәт өчен түләү шартлары нигезендә яки хезмәт шартнамәсе нигезендә эшләгән вакыт өчен пропорциональ рәвештә билгеләнә.

7. Эш бирүче вакытлыча характердагы эш урынына урнаштырылган граждан белән вакытлы хезмәт шартнамәсе төзи.

Эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләр арасындагы гражданнар белән эш бирүче вакытлыча булдырылган эш урыннарында берьюлы берничә эш башкару (читтән килеп яки оешма эчендә берничә эштә эшләү) өчен вакытлы хезмәт шартнамәләре төзи.

## II. Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибе һәм шартлары

8. Компенсация алу өчен эш бирүче агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең үзе төп эшчәнлеген гамәлгә ашырган урындагы дәүләт учреждениесенә (алга таба – эш белән тәэмин итү үзәге) Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы раслаган форма буенча гариза (алга таба – гариза) тапшыра. Күрсәтелгән вакыттан соңрак кертелгән гаризалар каралмый.

Эш бирүченең гаризасы эш белән тәэмин итү үзәгенә кергән көнендә теркәлә.

9. Эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә эш бирүче белән оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан гражданнарны һәм эш эзләүче гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча уртак эшчәнлек турында Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) раслый форма буенча шартнамә (алга таба – шартнамә) төзи.

10. Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарының һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан эш бирүче һәм эш белән тәэмин итү үзәге арасында төзелгән шартнамә шартлары нигезендә башкарыла.

11. Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасындагы вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарының һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләүгә акча күчерүне эш белән тәэмин итү үзәге аванс түләве рәвешендә яки документларның эш бирүче таныклаган түбәндәге күчермәләре кертелгән шартларда хезмәт өчен түләүгә фактта тотылган чыгымнарны каплау юлы белән кимендә айга бер тапкыр гамәлгә ашыра:

вакытлыча эш урыннары булдыру турындагы боерыкның;

граждан белән төзелгән вакытлы хезмәт шартнамәсенең;

эшкә кабул итү турындагы боерыкның;

эш вакытын исәпкә алу табеленең;

исәп-хисап ведомостенең (эш хакының исәпләнгән суммасы турында) – аванс түләве рәвешендә компенсация бирелгәндә;

бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре буенча исәпләнгән акча исәп-хисабының;

түләү ведомостенең (түләнгән эш хакы суммасы турында) яки эш хакы суммасын гражданнарның кредит оешмаларындагы шәхси исәпләренә күчерү турындагы түләү йөкләмәсенең – хезмәт өчен түләүгә фактта тотылган чыгымнарны каплау өчен компенсация бирелгәндә;

бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен күчерү турындагы түләү йөкләмәсенең.

12. Аванс түләве рәвешендә бирелгән, агымдагы елның 31 декабренә кадәр файдаланылмаган компенсация акчасы суммасын эш бирүче 2016 елның беренче ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга тиеш.

## III. Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау чыгымнарын финанслау тәртибе

13. Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү чыгымнарын финанслау Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

14. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – Федераль казначылык идарәсе) федераль бюджеттан акча керү турында мәгълүмат алганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә Министрлыкка Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы шәхси исәбеннән акча күчерү өчен федераль казначылык идарәсенә чыгымнар расписаниесен кертә.

15. Министрлык Федераль казначылык идарәсеннән Министрлыкның шәхси исәбенә акча керү турындагы чыгарма нигезендә акчаны Министрлык билгеләгән лимитлар нигезендә эш белән тәэмин итү үзәкләре исәпләренә күчерә.

16. Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауны Министрлык тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан

Республикасы бюджетында бу максатларга күздә тотылган акча күләмнәре нигезендә гамәлгә ашыра.

17. Министрлык тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган акча чикләрендә акчаны Министрлык билгеләгән лимитлар нигезендә эш белән тәэмин итү үзәкләре исәпләренә күчерә.

18. Эш белән тәэмин итү үзәкләре акча аларның исәпләренә кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә кергән акчаны Тәртиптә һәм шартнамәдә күздә тотылган шартларда эш бирүчеләр исәпләренә күчерә.

19. Министрлык квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 еннән дә соңга калмыйча, финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм оешмаларның эштән азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләрен һәм эш эзләүче гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруга субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткечләрнең мәгънәләренә ирешү хакында Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына хисап кертә.

20. Агымдагы елның 31 декабренә кадәр файдаланылмый калган әлеге акча шартнамәләрдә күздә тотылган очракларда 2016 елның беренче ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

21. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга бүлеп бирелгән бюджет акчасын бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүгә законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерү гамәлгә ашыра.

22. Оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү өчен эш бирүчегә бирелгән акчаны эш бирүче түбәндәге очракларда эш белән тәэмин итү үзәгенең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга тиеш:

оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү чыгымнары буенча эш бирүченең дөрес булмаган мәгълүматлар кертү фактлары ачыкланганда;

максатчан файдаланмаганда;

шартнамәдә каралган башка шартлар үтәлмәгәндә.

Оешмаларның эштән азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешенә компенсация максатчан

файдаланылмаса, ул максатчан файдаланылмаган өлеше суммасында кире кайтарылырга тиеш.

23. Эш бирүче компенсация акчасын кире кайтару буенча бу Тәртипнең 12, 20 нче яки 22 нче пунктларында билгеләнгән вакытны бозган очракта, Министрлык күрсәтелгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.

24. Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык  һәм эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---

F:\KARAR\2015\219-1.docx